РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ САРДЕКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘРДЕКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422126, Сәрдекбаш авылы, Үзәк урам, 45. тел./факс: (884364) 25-0-43 e-mail: Sard.Kuk@tatar.ru.

КАРАР

31 июль, 2024 ел

№ 30

Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, Саәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 ноябрендәге 29 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 42 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 23 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып (алга таба – Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Түбәндәге эчтәлектәге 3.1 бүлеген өстәргә:

«3.1. Дәүләт бүләге бирү яки бүләкләү өчен бер тапкыр бирелә торган акча

1. Муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, шулай ук түләүгә яисә бүләк бирүгә тәкъдим ителгәннән соң муниципаль хезмәттән азат ителгән Россия Федерациясе гражданнарына (алга таба шулай ук – гражданнар) түбәндәге күләмдә бер тапкыр бирелә торган акча түләнә:

а) Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бүләкләнгәндә – биләгән вазыйфасы нигезендә 0,5 вазыйфаи хезмәт хакы (акчалата бүләкләү) күләмендә;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге белән бүләкләгәндә – биләгән вазыйфасы нигезендә 1,5 вазыйфаи хезмәт хакы (акчалата бүләкләү) күләмендә;

в) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан бүләкләнгәндә – бер вазыйфаи хезмәт хакы (акчалата бүләкләү) күләмендә;

г) Россия Федерациясенең Дәүләт бүләге белән бүләкләгәндә – ике вазыйфа окладь (акчалата бүләкләү) күләмендә.

2. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү бүләкләү яки бүләк бирү турында Россия Федерациясе хокукый акты яки Татарстан Республикасы хокукый акты басылган көнгә, ә гражданнарга карата –аларны эштән азат итү турында хокукый акт чыккан көнгә билгеләнгән вазыйфаи хезмәт хакы (акчалата бүләкләү) күләменнән чыгып түләнә.

3. Бер тапкыр бирелә торган бүләкләү күрсәтелгән затны җирле үзидарәнең тиешле органының хезмәткә түләү фонды акчалары хисабына бүләкләү яки бүләк бирү турында Россия Федерациясе хокукый акты яки Татарстан Республикасы хокукый акты басылган көннән соң 30 көн эчендә күрсәтелгән зат муниципаль хезмәт вазыйфасын (муниципаль вазыйфаны) башкара торган яки башкарган җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла. »

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Җирлек башлыгы: И.М. Набиев